ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.05.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1142**

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның, 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законның аерым нормаларын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

2.1 Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 10 апрелендәге 744 номерлы карарының 1.55 пункты;

2.2 Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 10 апрелендәге 744 номерлы карарына «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 55 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында»гы 2283 номерлы карары.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев